РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ | КАРАР

29 октябрь 2021 ел | №18

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына (2018 елның 5 июнендәге 10 номерлы, 2019 елның 24 маендагы 7 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 31 номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 9 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 41 нче пунктны өстәргә:

«41) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу.»;

1.2. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 нче пунктны өстәргә:

«18) алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

1.3. 10 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктны өстәргә:

«5.1.) инициативалы проектлар;»;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 15.1 статьясын өстәргә:

«15.1 статьясы Инициативалы проектлар

1. Җирлек халкы яки аның өлеше өчен өстенлекле булган чараларны гамәлгә ашыру максатыннан, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яки җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча, Җирлек башкарма комитетына инициативалы проект кертелергә мөмкин. Инициативалы проектлар гамәлгә ашырылырга мөмкин булган җирлек территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Инициативалы проектны кертү инициативасы белән, җирлек территориясендә яшәүче һәм уналты яшькә җиткән кимендә ун гражданнан торган

инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары (алга таба– проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны җирлек Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Җирлек Советының норматив хокукый акты нигезендә проект инициаторы булып чыгу хокукы шулай ук тиешле җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициативалы проект үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

1) хәл итү җирлек яки аның өлешенең халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү;

5) инициативалы проектны гамәлгә ашыруның планлаштырылган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынган затларның планлаштырылган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яки) хезмәт катнашуы турында белешмәләр;

7) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен, планлаштырылган инициатив түләүләр күләменнән тыш, әлеге акчаларны файдалану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтмә;

8) җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә чикләрендә инициативалы проект гамәлгә ашырылырга мөмкин җирлек территориясенә яисә аның өлешенә күрсәтмә;

9) җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициативалы проект, аны җирлек Башкарма комитетына керткәнче, гражданнарның җыенында, җыелышында яки конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яки конференциясендә, инициативалы проект турында фикер алышу, аның җирлек яки аның өлешенең халкы мәнфәгатьләренә туры килүен, инициативалы проектны тормышка ашыруның максатка ярашлыгын билгеләү, шулай ук гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе тарафыннан инициативалы проектка ярдәм итү турында карар кабул итү максатында карап тикшерелергә тиеш. Шул ук вакытта бер җыенда, бер җыелышта яки гражданнарның бер конференциясендә берничә инициативалы проектны карау мөмкин.

Җирлек Советының норматив-хокукый акты белән инициатив проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен, шулай ук гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Җирлек башкарма комитетына инициативалы проектны керткәндә, проект инициаторлары аңа тиешле рәвештә гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе беркетмәсен, гражданнар арасында сораштыру нәтиҗәләре һәм (яки) җирлек яки аның өлешенең халкы тарафыннан инициативалы проектны хуплауны раслый торган имзалар кәгазен теркиләр.

5. Җирлек Башкарма комитетына инициативалы проектны кертү турындагы мәгълүмат инициативалы проект җирлек Башкарма комитетына кертелгәннән соң өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

җирлекнең рәсми сайтында бастырылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш һәм анда әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләр булырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга җирлек Башкарма комитетына инициативалы проект буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен бирү мөмкинлеге турында хәбәр ителә, тапшыру вакыты күрсәтелә, аларны тәкъдим итү вакыты биш эш көненнән дә ким булмаска тиеш. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яше тулган җирлек халкы җибәрергә хокуклы. Җирлек Башкарма комитетының әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән мәгълүмат Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүмат гражданнарга территориаль иҗтимагый үзидарә органнары тарафыннан җиткерелергә мөмкин.

6. Инициативалы проект җирлек Башкарма комитеты тарафыннан, аны керткәннән соң 30 көн эчендә, мәҗбүри каралырга тиеш. Җирлек Башкарма комитеты инициативалы проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициативалы проектны хупларга һәм җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибе (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) нигезендә аның өстендә эшләүне дәвам итәргә;

2) инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тартырга һәм, инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, проектны инициаторларына кире кайтарырга.

7. Җирлек башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициативалы проектка ярдәм итүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициативалы проектны кертү һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициативалы проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, җирлек уставы таләпләренә туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициативалы проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган акчалар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау, аларны формалаштыру чыганагы инициативалы түләүләр булмаганда;

5) инициативалы проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

8. Җирлек башкарма комитеты проект инициаторларына инициативалы проектны бергәләп эшләп бетерергә шулай ук аны аны башка җирлекнең җирле үзидарә органына яисә дәүләт органына үз компетенцияләре нигезендә карауга бирергә тәкъдим итәргә, хокуклы, ә әлеге статьяның 7 пунктындагы 5 пунктчасында каралган очракта, бурычлы.

9. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен күрсәтелә торган инициатив проектларга карата инициативалы проектларда булырга тиешле белешмәләр составына карата таләпләр, инициативалы проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Россия Федерациясе субъектының закон һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12пунктларның таләпләре кулланылмый.

11. Әгәр җирлек башкарма комитетына берничә инициативалы проект кертелгән булса, шул исәптән охшаш өстенлекле проблемаларны тасвирлау белән, Җирлек башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проект инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аның формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә. Коллегиаль орган (комиссия) составы җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан формалаштырыла. Шул ук вакытта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санынннан яртысы җирлек Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган (комиссия) тарафыннан инициативалы проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проект инициаторлары, гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе вәкаләт биргән җирлек территориясендә яшәүче башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициативалы проектны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашыруны иҗтимагый контрольдә тотарга хокуклы.

14. Җирлек Башкарма комитетының инициативалы проектны каравы, инициативалы проектны тормышка ашыруның барышы, шул исәптән акча средстволарын куллану, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәт һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Җирлек Башкарма комитетының инициативалы проектны тормышка ашыру нәтиҗәләре турындагы хисабы инициативалы проектны тормышка ашыру тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Җирлек Башкарма комитетының әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән мәгълүмат Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүмат гражданнарга территориаль иҗтимагый үзидарә органнары тарафыннан җиткерелергә мөмкин.»;

1.5. 16 статьяны түбәндәге эчтәлектәге10.1 пункты белән тулыландырырга:

«10.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициативалы проектны проект инициаторлары сыйфатында тәкъдим итә алалар.»;

1.6. 20 статьяда:

ә) 1 пунктка «һәм җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи затларын» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу» сүзләрен өстәргә

б) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

1.7. 22.1 статьясында:

а) 4 пунктта «анда торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашканда» сүзләреннән соң (яисә аның территориясенең бер өлешен) яисә җирлектә.» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 10 нчы пунктны өстәргә:

«10. Торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены җирлек составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә үткәрелергә мөмкин.

Мондый гражданнар җыены Кукмара шәһәре Советы тарафыннан, кимендә 10 кешеле торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче халык төркеме инициативасы буенча чакырыла.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре Кукмара шәһәре Советы карары белән торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә гомуми мәнфәгатьләре критерийларыннан чыгып билгеләнә.»;

1.8. 39 статьяда 1 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

1.9. 45 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 статья. Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Җирлек башлыгы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булу;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 741 статьясы нигезендә отставкага чыгару;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан читләштерү;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип тану;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип тану яисә вафат булган дип игълан итү;

7) аңа карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

8) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына китү;

9) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;

10) сайлаучылар ихтыяры белән чакыртып ал (отзыва избирателями);

11) сәламәтлек торышы буенча суд тәртибендә билгеләнгән җирлек башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсезлек дәрәҗәсе буенча;

12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору;

13) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү аркасында муниципаль берәмлек сайлаучыларының санын 25 проценттан күбрәккә арттыруны.

2. Әгәр җирлек Советының вәкаләтләре вакыты чыкканчы алты айдан да ким вакыт калса, җирлек Башлыгын сайлау яңа сайланган җирлек Советының беренче утырышында башкарыла.

3. Җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа җирлек Башлыгы җирлек Советының якындагы утырышында, вәкаләтләре туктатылган көннән алты айдан да артмаган срокта сайлана.

Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң алты ай узгач, яңа җирлек Башлыгы сайланган җирлек Советы утырышын яшь буенча иң өлкән депутат алып бара.

Депутат, әгәр аны сайлау өчен җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, җирлек Башлыгы итеп сайланган дип санала.

4. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки саңа суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен җирлек Башлыгы урынбасары башкара.

Җирлек башлыгы урынбасары булмаганда, җирлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча җирлек Советының якындагы утырышында башка депутатлар, депутатларның инициатив төркемнәре тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан сайланган җирлек Советы депутаты башкара.

Җирлек Башлыгы урынбасары яисә җирлек Советы депутаты тарафыннан Җирлек Башлыгы вәкаләтләрен башкару вакыты җирлекнең элеккеге Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып алты айдан артмаска ти-

еш.»;

1.10. 48 статьяда:

а) 1 пунктның 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«41) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнаша»;

б) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә

«- алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.»;

1.11. 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 нче пунктны өстәргә:

«7) Җирле администрация башлыгы муниципаль берәмлек башлыгына чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит дәүләт гражданлыгын туктату турында, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яки Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында, яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия чит ил гражданына бу турыда мәгълүм булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы туктатылган көннән алып, яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган яисә әлеге пунктта каралган яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә башка документ алган көннән башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.»;

1.12. 53 статьяда 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»;

1.12. түбәндәге эчтәлекле XI.1 бүлеген өстәргә:

XI.I. бүлеге МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ УЗУ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮ

75.1 статьясы Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт – гражданнарның хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган һөнәри эшчәнлеге.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәтне финанслау Җирлек бюджеты аччалары хисабына башкарыла.

4. Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнар муниципаль хезмәткә тигез хокуклы һәм аның җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый

берләшмәләргә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга бәйсез рәвештә узу шартлары тигез.

муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен кирәкле һөнәри белем бирү дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын классификацияләү нигезендә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәк булган белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе белән шулай ук белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралырга мөмкин.

5. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләү, муниципаль хезмәт үтү шартлары һәм тәртибе Федераль закон, шулай ук аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары, әлеге устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

75.2 статьясы Муниципаль хезмәт вазыйфасы

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – җирле үзидарә органында, Җирлекнең Сайлау комиссиясе Аппаратындагы әлеге Устав нигезендә җирле үзидарә органының, Сайлау комиссиясенең яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләренең үтәлешен тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе нигезендә төзелә торган вазыйфа.

75.3 статьясы Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар — җирлек Советы депутаты, җирлек Башлыгы, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы җирлек сайлау комиссиясенең даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы.

2. Муниципаль хезмәткәр – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, Җирлекнең җирле бюджеты акчалары исәбеннән түләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфасы бурычларын башкара торган гражданы.

3. Җирле үзидарә органнары, җирлек Сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләми һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

75.4. статьясы Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр

1. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр гарантияләнә:

1) вазыйфаи бурычларын вазыйфаи инструкция нигезендә үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) акчалата түләүне не үз вакытында һәм тулы күләмдә алу хокукы;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләп, ял көннәре һәм эшләми торган бәйрәм көннәре биреп, шулай ук ел саен түләнә торган түләүле ял итү биреп тәэмин ителә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыккач та, медицина хезмәте күрсәтү;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлык белән бәйле рәвештә пенсия белән тәэмин итү, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларын, аның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән үлеме очрагында, пенсия белән тәэмин итү;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян салынган очракка мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә ул туктатылганнан соң, әмма аның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә килеп туган авыруы яки хезмәткә сәләтен югалтуы очрагына мәҗбүри дәүләт социаль иминиятләштерүе;

8) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда аларның вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле көч кулланудан, янаулардан һәм башка хокуксыз гамәлләрдән яклау.

2. Җирле үзидарә органы, җирлекнең сайлау комиссиясе юкка чыгуга йә җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләренең штаты кыскаруга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүе өзелгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма бетерелүгә йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле рәвештә хезмәткәрләр эштән азат ителгән очракта, хезмәткәрләргә хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Муниципаль хезмәттән киткәндә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акча (поощрение) түләнә. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү шартлары, күләме һәм тәртибе, җирлек Советы тарафыннан расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.»;

1.13. түбәндәге эчтәлекле 85.1 статьяны өстәргә:

«85.1. статьясы Инициативалы проектларны тормышка ашыруны финанс һәм башка яктан тәэмин итү

1. Әлеге уставның 15.1 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып инициатив проектларны гамәлгә ашыруга җирлек бюджеты турындагы карар белән каралган, шул исәптән җирлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып төзелә торган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициативалы түләүләр дигәндә гражданнарның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затларның ихтыярый нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында җирле бюджетка күчерелә торган акчалары аңлашыла.

3. Әгәр дә инициативалы проект гамәлгә ашырылмаган булса, инициативалы түләүләр җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча инициативалы проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициативалы түләүләр калдыгы барлыкка килгән очракта,

күрсәтелгән түләүләр җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш.

Аларны җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициативалы түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициативалы проектларны тормышка ашыру, шулай ук, кызыксынган затларның ирекле милек һәм (яки) хезмәт катнашуы рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин».;

1.14. 92 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек Уставы, җирлек Советының җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Авыл җирлеге башлыгы теркәлгән уставны, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы турында, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү хакында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырырга (халыкка җиткерергә) бурычлы».

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Кукмара шәһәре Мэры С. Д. Димитриев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД КУКМОР КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ * ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ * Совет города Кукмор ИНН 1623001484 Кукмара шәһәре Советы